РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Сарлинского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 68А, Азнакаевский район,
с.Сарлы, 423315,
тел./факс (885592)36-5-34
E-mail: Sarl.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге
башкарма комитеты

Үзәк ур., 68 А йорт, Азнакай районы,
Сарлы авылы, 423315
тел./факс (885592)36-5-34
E-mail: Sarl.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«06» апрель, 2023 ел** **№18**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 13 ноябрендәге 17 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге территориясен планлаштыру буенча документация әзерләү тәртибен раслау турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге территориясен планлаштыру буенча документлар әзерләү тәртибенә үзгәреш кертү турында (2018 елның 18 маендагы 11 номерлы, 2019 елның 03 апрелендәге 15 номерлы, 2019 елның 17 октябрендәге 31 номерлы карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьяның 2 пунктының икенче абзацы үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең башкарма комитеты **карар итә:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 13 ноябрендәге 17 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге территориясен планлаштыру буенча документация әзерләү тәртибен раслау турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге территориясен планлаштыру буенча документлар әзерләү тәртибенә (2018 елның 18 маендагы 11 номерлы, 2019 елның 03 апрелендәге 15 номерлы, 2019 елның 17 октябрендәге 31 номерлы карарлар редакциясендә) 2.14 пунктында «бер ай

һәм өч айдан артык» сүзләрен «ундүрт көн һәм утыз көннән артык» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://aznakayevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Л.М.Хаҗиев